| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯШЕЛ ҮЗӘН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 16 феврале №5

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2020 елның 14 маендагы 9 номерлы Олы Ачасыр авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге башкарма комитеты **карар итә:**

1. Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 14 маендагы 9 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентны 1.2. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба- мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, бу хезмәт күрсәтүне алу шарты булып тора.»;

1.2. «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» дигән 2 нче графанын 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча өстәргә:

2) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы (булуы) турында белешмә, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш.».

1.3. «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» дигән 2 нче графанын 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

5) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш) булуы.».

1.4. 3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирү турында запрос җибәрә:

Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар).

Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы (булуы) турында белешмә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрос.»

1.5. Агач һәм куакларны кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү турында гариза (Административ регламентның 1 нче кушымтасы) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шәхси мәгълүматлар турында»гы 27.07.2006 ел №152-ФЗ Федераль законның 9 статьясы нигезендә, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Яшел Үзән муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы М.Г. Гатиятуллин